КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 15 октябрь г.Казань № 884

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен раслау турында» 2024 ел, 27 май, 368 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасында муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрне шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибен раслау турында» 2024 ел, 27 май, 368 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның икенче абзацына «(алга таба - Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. 2024 елда түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына юллама алуга исәптә торучы пенсионерлар һәм 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнар (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) арасыннан гражданнар (алга таба - пенсионерлар), аларның ризалыгы белән чират тәртибендә Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибе

нигезендә электрон сертификат бирү юлы белән шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин ителергә мөмкин;

пенсионерга электрон сертификат бирү пенсионерның яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы (алга таба - территориаль орган) тарафыннан электрон сертификат алуга гариза нигезендә гамәлгә ашырыла, ул пенсионер тарафыннан территориаль органга Шифаханә-курорт дәвалавын оештыру тәртибенә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча ул электрон сертификаты булу турында хәбәрнамә алганнан соң бирелә;

территориаль орган пенсионерга Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 2.2 пунктының 2.2.4 пунктчасы нигезендә билгеләнә торган чиратлылык нигезендә электрон сертификаты булу турында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан пенсионерга бирү өчен электрон сертификат барлыгы турында мәгълүмат кергән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә хәбәр итә;

әлеге пункт нигезендә электрон сертификат алган пенсионерлар Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә юллама алу исәбеннән төшерелә;

әлеге пунктта каралган чыгымнарны финанслау «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе нигезендә шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итүгә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин